## БЕЗНЕҢ ИШЕГАЛДЫ
Уңайлы мохит өчен тавыш биреп була

> 2

## ЧӘЙЛЕ ТАБЫН
Район башлыклары ялга кайткан солдатларны тыңлый

> 3

## ЮГАЛТУ
Татар җәмәгатьчелеге танылган баянчы Рәшит Мостафин белән хушлашты

> 3

## САБАНТУЙ КАЙТАВАЗЫ
Авыл, районнарда узган бәйрәм ниләр белән истә калды?

> 4


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 83 (29050) | Чәршәмбе | 14 июнь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

# ТЫНГЫСЫЗ ҖӘЙ
## ТАТАРСТАНДА ИМГӘНГӘН БАЛАЛАР САНЫ АРТА

**Баладан бигрәк ата-аналарның үзләрен өйрәтергә кирәк! Имгәнгән балаларга ярдәм күрсәтүче бер төркем табиб шулай дип күрсенә. Баланың ни сәбәпле имгәнүен сораша башлагач, күпләр «алай булыр дип белмәдем», «күрмәдем», «мин аны белә дип торам» ише җаваплар яудыра икән. Балалар белән килеп чыккан күңелсез очракларның күбесенә телефоннан аерыла алмаган замана ата-аналарының игътибарсызлыгы гаепле, ди белгечләр.**

Табиблар яшерми: җәйге чорны куркып көтә алар. Ник дигәндә, нәкъ менә шушы чорда имгәнгән балалар саны бермә-бер арта. Быел да искәрмә булмаган. Җәй башланганнан бирле Республика клиник балалар хастаханәсенә көненә 130лап имгәнгән баланы алып киләләр икән. Шуларның яртысына «сыну» диагнозы куела. Балаларның күбесе велосипед яки самокатта йөргәндә җәрәхәтләнә. Аларның, нигездә, кул-аякларына зыян килә икән.

– Балаларның сынган кул-аягы бик озак төзәлә. Кемгәдер моның өчен бер ай вакыт таләп ителә, икенче берсенеке өч айга ук сузылырга мөмкин. Бер ел дәвамында тернәкләнгән балалар да бар, – дип сөйләде Республика клиник хастаханәсенең амбулатор травматология һәм ортопедия бүлеге җитәкчесе Ленар Дзюменко журналистлар белән очрашуда.

*Имгәнүче балалар саны ел саен 10–20 процентка арта бара, ди белгечләр. Алар моны балалар өчен төзелгән ял урыннары санын күбәюгә бәйләп аңлата. Чагыштыру өчен: узган ел республикада барлыгы 120 мең бала имгәнгән. Аннан алдагы елда бу сан 20 процентка азрак булган.*

Быел Татарстанда тәрәзәдән егылып төшеп имгәнгән балалар саны да арткан. Әле җәй башланырга да өлгермәде, республикада шул рәвешле өч бала зыян күрде. Аларның берсе шундук вафат булган. Әлеге фаҗигаләр Алабуга, Түбән Кама, Казанда килеп чыкты. Узган елның шул ук чорында республикада мондый фаҗигаләр өч тапкыр азрак теркәлгән.

Республика клиник балалар хастаханәсенең хирургия ярдәме буенча баш табиб урынбасары Михаил Поспелов сүзләренә караганда, ел башыннан Татарстанда барлыгы 14 бала тәрәзәдән егылып төшкән, өчесенең гомере өзелгән. Имгәнгән балаларның, нигездә, баш сөяге, аяк-кулларына, баш миенә зыян килгән. Умыртка баганасы сынучылар да шактый. Эчке органнарга кан саву очраклары да бар. Белгеч бу урында табиблар елныңелында искәртеп торган кагыйдәләрне искә төшерергә мәҗбүр.

– Мондый фаҗигаләрне кисәтү тулысынча ата-ана җилкәсендә. Кечкенә баланың бар нәрсәне эшләп, капшап, тотып карыйсы килә бит. Шуңа күрә балаларны өйдә үзләрен генә калдырырга ярамый. Абыйапалары белән генә калдыру да куркыныч. Ник дигәндә, алар еш кына гаджетларда утыра, балада гамьнәре булмый, – ди табиб. – Тәрәзә яннарында урындык, өстәл кебек җиһазлар да тормаска тиеш. Алар ярдәмендә бала тәрәзә төбенә җайлы гына менә ала. Аннары ата-ана шуны да онытмасын иде: тәрәзәгә куелган москит челтәре егылудан сакламый, чебен-черкидән генә коткара. Шуңа күрә тәрәзәгә чикләгеч яки йозак куюдан да яхшысы юк.

Табибларга баш мие җәрәхәтләре белән китерелгән балалар саны да арткан. Табиб-нейрохирург Владимир Иванов сүзләренә караганда, аларның бүлегенә көн саен шундый җәрәхәт алган 5–10лап баланы китерәләр икән. Аларның да күбесе шул ук самокат, велосипедта саклагыч җайланмалардан башка гына йөргәндә имгәнгән.

– Ата-ана баласына шундый кыйммәтле уенчык алып бирергә акчасын таба. Ә менә анда йөргәндә башны, аяк-кулларны саклый торган җайланмаларга акча кызгана. «Ник алмадыгыз?» – дип сорагач: «Бу турыда уйлап та караганым булмады», – диләр. Менә шундый шаккаткыч җаваплар алабыз, – дип аптырый табиб.

Ахыры 2 нче биттә >

Илдар Мөхәммәтҗанов

**Эльза ӘХМӘДУЛЛИНА,**
**Республика клиник балалар хастаханәсенең тернәкләндерү бүлеге мөдире:**
– Без имгәнү, җәрәхәтләнүләр аркасында бала организмына салынган зыянны киметергә, аны инвалидлыктан саклап калырга тырышабыз. Әмма кайчак хәлләр шулкадәр мөшкел була ки, хәтта без кулланган тернәкләндерү ысуллары да ярдәм итми. Шуңа күрә ата-ана эшне бу дәрәҗәгә җиткермичә, баласын имгәнү-җәрәхәтләрдән сакласын иде. Муен, арка өлешенә зыян килгән балаларның күбесе еш кына инвалид кала. Бер генә имгәнү дә баланың организмында эзсез югалмый. Әйтик, баланың баш миенә зыян килгән булса, ул тернәкләнеп, элеккечә үк мәктәпкә укырга йөрергә мөмкин. Әмма аның үсеше дә, баш мие эшчәнлеге дә элеккеге дәрәҗәдә булмаячак инде. Шул ук уку, язуында да хилафлыклар килеп чыгарга мөмкин. Җитди имгәнгән баланы тулысынча аякка бастыру бик кыен. Күптән түгел генә анализ ясаган идек. Соңгы биш елда җитди баш мие җәрәхәте алган 50 баланың 20се әле дә бездә даими рәвештә тернәкләнү уза.

# Солдатка сәлам юлла!

Махсус хәрби операциядә катнашучыларга посылка һәм хатларны бушлай юллау мөмкинлеге булдырылган. Аларны Россия Кораллы Көчләренең фельдъегерь-почта элемтәсе бүлекләре тапшыра.

Татарстан Хәрби комиссариатының гражданнар белән эшләү бүлеге башлыгы Сергей Котин әйтүенчә, хәрбиләргә 10 килограммга кадәрге авырлыктагы посылкалар бушлай юллана. Аларны теләсә кайсы почта бүлегеннән җибәрергә мөмкин.

Илнең төрле почмакларыннан посылкалар Россия почтасының Мәскәүдәге логистика үзәгендә туплана. Шуннан соң алар Оборона министрлыгы вәкилләренә тапшырыла.

Посылканы бары тик почта бүлекләре аша гына бушлай җибәрергә мөмкин. Операторга аны ачык килеш тапшырырга кирәк. Бер кеше чикләнелмәгән санда посылка җибәрә ала. Әмма һәркайсының авырлыгы 10 килодан артмаска тиеш.

Хатлар гадәти конвертка салып юллана. Хат һәм посылкаларга адресны түбәндәгечә язарга: 103400, город Москва-400, адресатның ФИО, хәрби часте номеры.

# *Сыерлар ишәя*

Апрель ахырына Татарстанның барлык төрдәге хуҗалыкларында җәмгысы 924,9 мең баш мөгезле эре терлек исәпләнгән. Узган елның шушы ук чорындагыга караганда бу сан 0,9 процентка кимрәк. Шул ук вакытта сыерларның ишәюе теркәлгән. Апрель ахырында аларның баш саны 325,6 меңгә җиткән (2022 елдагы белән чагыштырганда 1 процентка күбрәк). Республикада сарык һәм кәҗәләр саны 1,2 процентка кимеп, 341,8 меңгә, дуңгызлар 469,5 меңгә калган.

Татарстанда, элеккечә үк, кош-корт саны арта. Апрель ахырына аларның баш саны 19,3 миллион тәшкил иткән (узган елның шушы ук чорындагы белән чагыштырганда 2,2 процентка күбрәк).

# Урман бете котырган

Быел яз башыннан бирле Татарстанда 5069 кеше талпан кадалу сәбәпле табибларга күренергә мәҗбүр булган. Мондый очраклар 100 мең кешегә 135,36 күрсәткечен тәшкил итә. Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе хәбәренә караганда, бу сан күпьеллык уртача күрсәткечтән (99,31) 36,6 процентка зуррак.

Узган елның шушы ук чорында барлыгы 4483 кеше (100 мең кешегә – 120,4 очрак) медицина оешмаларына мөрәҗәгать иткән. Шулай итеп, быел әлеге күрсәткеч 13 процентка арткан.

Талпан кадалу очраклары, Әтнә һәм Тукай районнарыннан тыш, республиканың калган барлык районнарында теркәлгән. Бигрәк тә Казанда (1057 кеше), Чаллы (794) һәм Түбән Кама районында (423) табибларга мөрәҗәгать итүчеләр күп булган.

Бу бөҗәкләр Әгерҗе, Азнакай, Аксубай, Актаныш, Әлки һәм башка районнарда, шулай ук Казан һәм Чаллыда аеруча күп. Талпан кадалу очракларының 84,7 проценты шушы территорияләрдә теркәлгән.

Белгечләр кешеләрнең тәненнән алынган 1202 талпанны тикшергән. Шуның 224ендә талпан боррелиозы вирусы табылган.

# *Кисәтәләр*

Татарстан урманнарында, янгын куркынычы зур булу сәбәпле, янә кисәтү игълан ителде. Гидрометеоүзәк хәбәренә караганда, 13еннән 23 июньгә кадәр урманнарда урыны белән югары (4 класс) һәм гадәттән тыш югары (5 класс) янгын куркынычы саклана.

Җәй хикмәтләре

# Бакчага юрган ябасымы?

**Бу дүшәмбедә социаль челтәрләр Татарстанның төрле районнарында кыраудан зыян күргән яшелчә бакчасы фотолары белән тулды. Синоптиклар алдан кисәтсә дә, халык июнь уртасы җиткәндә бу кадәр суык булыр дип көтмәгән, ахры. Ачык һавага утырткан кыяр-помидор гына түгел, гомумән, бәрәңгесез калучылар да бар. Алда безне ни көтә?**

«Бәрәңге бакчасы кара янды…» Социаль челтәрләрдә мондый эчтәлектәге хәбәрләрне республиканың Саба, Арча, Кукмара, Биектау, Мамадыш, Актаныш, Әгерҗе районнарында яшәүчеләр күпләп язды.

– 12 июньгә каршы төндә төшкән кыраудан бөтен авыл зыян күрде. Күрше-тирә авылларда да шул ук хәл, – ди Әгерҗе районының Иске Эсләк җирле үзидарәсе бухгалтеры Гөлшат Идрисова. – Бәрәңге бакчасының карарлыгы да калмады. Помидор, кыяр, кабак ише үсентеләрне дә кырау сукты. Ачык һавага нәрсә утыртырга өлгерсәк, шул әрәм булды, кыскасы. Безнең якларда бәрәңге шактый зур үскән иде инде, аны 30 апрельдә үк утыртучылар да бар. Хәзер бөтен халык аптырашта. Әллә яңадан утыртыргамы икән, диләр. Орлыклык бәрәңге булса, көзгә кадәр уңыш өлгерә әле, ди өлкәннәр. Алдагы елларны августта бәрәңгене ала идек инде без. Быел сентябрь – октябрьдә дә бакчага чыгарга риза. Һава торышы гына булсын. Яңгыры да юк бит әле аның. Май буе рәтләп яңгыр күргән юк. Яңгыр яуса да, зыян күргән бәрәңгеләр бераз күтәрелеп китәр иде, бәлки. Кырау суккан бәрәңгенең уңышы ничек булыр, билгесез. Авылда яшәүче өлкәннәр әйтүенчә, моңа охшаш хәл 2007 елда булган. Июньнең уннары тирәсендә бакчаларны кырау сугып киткән, тик бу кадәр түгел. «Үсентеләр бик акрын күтәрелде», – дип искә алалар. Помидорлар да бик кызганыч. Сабак саен күпме помидор бар иде, хәзер барысы да каралып коела. Алдан кисәтсәләр дә, авыл җирендә бөтен бакчага юрган ябып бетереп булмый шул.

Һәвәскәр бакчачы Нурия Хафизова әйтүенчә, бәрәңге ун-унбиш сантиметр тирәсе генә үсәргә өлгергән булса, кырау сугу әллә ни куркыныч түгел. «Бәрәңге яңа ботаклар чыгарып, рәтләнеп китәчәк, әмма уңышы кимеячәк. Чәчәккә бөреләнгән бәрәңгене кырау суккан икән, аны яңадан утыртуың хәерлерәк. Зыян күргән яшелчәләргә күп итеп су сибегез», – ди бакчачы.

– Мондый елны күргәнем юк, – ди Балтач районының Янгул авылында яшәүче халык синоптигы Әмир Шәрәфиев. – Мин 1978 елдан бирле табигатькә бәйле күзәтүләр алып барам. Июньнең беренче көннәрендә кырау суккан очраклар булды, тик июнь уртасына җиткәндә – юк. Дөрес кырау булмады ул. Әби-бабайлар элек-электән, 8 июньнән соң кырау төшми, дип әйтәләр иде. Хәер, бу ел башыннан ук дөрес башланмады. Хәтерләсәгез, кыш көне яңгыр яуды да суытты, кач ману, хут суыклары булмады, карга, сыерчык бураннары килмәде, ләйсән яңгыр яумады. Кырауны июньнең бишесенә кадәр булырга мөмкин, дип көткән идем анысы. Бездә дә 12 июньгә каршы төндәге кыраудан зыян күрүчеләр булды. Төньяктан искән җил тәбәнәк, җилле урыннарда яшелчәләрнең яфракларын ялап киткән. Июнь салкынча булса да, июльдә җылытачак дип уйлыйм. Явым-төшемнәр урып-җыю вакытына калырга мөмкин. Көн озынаюдан туктагач, табигать тагын бер тапкыр көйсезләнеп тә алмагае әле. Боз яварга, җил-давыл чыгарга ихтимал. Мондый хәлләрнең булмавы хәерлерәк, әлбәттә.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

**Инна СВЯТЕНКО,**
**Федерация Советының Социаль сәясәт буенча комитет рәисе:**

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, 18 яшькә кадәрге ун яшүсмернең тугызы эшләргә теләк белдерә. Бу бит акча эшләү генә түгел, төрле һөнәрләргә кызыксыну да уяна дигән сүз. Димәк, аларга курьер яки реклама флайеры булып йөрүне генә түгел, бәлки, киләчәктә файдаланырлык һөнәрләрне дә тәкъдим итәргә кирәк.

**(«Парламентская газета»дан)**

# ТАТАРСТАНДА – ТОРАК БӘЯСЕ

**Татарстанстат мәгълүматлары буенча, республикада бу елның гыйнвар – март айларында беренчел торак базарында бәяләр, узган елның IV кварталы белән чагыштырганда, 0,6 процентка төшкән.**

(бер квадрат метр)

| | |
|---|---|
| **Татарстан** | **127095 мең** |
| Түбән Новгород өлкәсе | 124262 мең |
| Башкортстан | 110901 мең |
| Пермь крае | 101530 мең |
| Самара өлкәсе | 97700 мең |
| Киров өлкәсе | 88702 мең |
| Пенза өлкәсе | 87744 мең |
| Удмуртия | 86502 мең |
| Чувашия | 83829 мең |
| Ульяновск өлкәсе | 82857 мең |
| Саратов өлкәсе | 73001 мең |
| Мордовия | 70160 мең |
| Мари Эл | 65498 мең |
| Оренбург өлкәсе | 63384 мең |


Реклама 16+

# Сөенечле хәбәр!

**2023 елның 5–15 июнь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!**

**П2435** җомга саны — Ташламалы бәя **444 сум 54 тиен**, гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

**П2409** атнага дүрт тапкыр чыга — Ташламалы бәя **1051 сум 80 тиен**, гадәти бәясе – ~~1227 сум 30 тиен~~



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

**Дөньяда**

## КИЛӘЧӘК КЕМ КУЛЫНДА?

Глобаль державалар үзләренең үсеш потенциалларын югалтып бара. Соңгы көннәрнең статистикасы һәм геосәясәт мәйданында барган вакыйгалар шундый нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. АКШта соңгы 39 елда банк депозитларыннан акчалар качуның рекордлы масштабы күзәтелә. ФРС моның киресен расларга, язгы банк кризисы тәгәлләнде дигән фикер уздырырга теләсә дә, фактлар үҗәт рәвештә катастрофик үсеш сценариен күрсәтә. Банк депозитларында акча күләме 472 миллиард долларга кимегән. Американнар дәүләт әҗәтенең «түшәм»ен күтәрделәр күтәрүен, әмма аның процентларын түләп бару өчен генә дә елга 1 триллион долларга якын акча тотарга кирәк. Бу Россиянең федераль бюджетыннан өч тапкырга якын күбрәк. АКШның үз хәрби бюджетын 20 процентка узып китә.

Дөнья икътисадының төп моторы булып саналган Кытайда да эшләр шәптән түгел. Алар, нык үскән державалар эзеннән барып, базарларын банк кредитлары хисабына үстерделәр. Вәләкин соңгы көннәрдә куллану кредитлары бирү шулкадәр кимеде: белгечләр аны җимерелү дип бәяләде. Корпоратив облигацияләр күләме дә кискен түбәнәйде. Кулланучылар белән бизнес өметсезлек зонасына кереп бара дигән сүз бу. Әлегә дәүләт финанслары тармагы һәм банк секторы актив рәвештә бурычка акча җыя, әмма бу инде үсешне тәэмин итми. Дөнья базарларында да Кытай товарларына ихтыяҗ кими. Май аенда анда экспорт та, импорт та нык түбәнәйде. Экспорт – 7,5, импорт 4,5 процентка кимегән. Бу дөнья базарларында да, эчке базарда да куллану сүлпәнәя дигән нәтиҗәгә китерә.

Дөнья икътисадының хәле шәп түгеллеген без бу саннардан башка да нефть котировкаларына карап белә алабыз. ОПЕК+ның июнь башында җыелып, «кара алтын» чыгару күләмен киметү турындагы карары углеводород базарларына тәэсир ясамады диярлек. Баррель башта печтек кенә кыйммәтләнде, аннан янә арзаная башлады.

Көчәеп баручы кризис шартларында ике держава – Кытай һәм АКШ Якын Көнчыгыш өчен кискен көрәш алып баралар. Фарсы култыгының нефть державалары әлегә Кытай тарафына авыша. Дөнья сәясәтендә Иранның роле көчәя. Кытайлар булышлыгы белән гарәп илләренең фарсылар белән килешү юлына басулары американнар теләмәгән һәм көтмәгән адым булды. АКШ та сәхнә артында Иран белән сөйләшүләр алып бара. Тәһранның Көнбатыш банкларында бикләнгән акчаларын кайтарып бирергә туры килмәгәе. Израильнең Maariv басмасы: «Иранда табылган литий ятмалары төбәктәге көч балансын үзгәртәчәк һәм илгә тиңе булмаган геосәяси статус бирәчәк», – дип язды. Белгечләр киләчәктә нефть түгел, литий сәнәгате төп байлык чыганагы булачак дип саныйлар. Фарсыларның литий ятмалары дөньяда икенче урында тора. Тәһран, тавыш тизлеген 12 тапкыр узып китүче (кайбер чыганаклар 15 дигән сан күрсәтә) тиңсез гипертавыш ракетасын сынадык, дип тә шаулый. Бу фарсыларның Көнбатыш державалары өчен каты чикләвеккә әверелеп баруларын күрсәтә. Якын елларда көчләр балансын үзгәртүче бөек вакыйгалар көтелә. Кемнең түбән төшүен, кемнең өскә калкуын, Аллаһ теләсә, шул чакта күрербез.

**Россиядә**

## БУРЫЧЛАР ИЛ БЮДЖЕТЫН УЗЫП КИТКӘНДӘ

Глобаль финанс системасының состав өлеше булган Россиядә дә кәгазь-электрон акча һәм процент капиталына бәйле проблемалар кискенләшә. Без яшәгән киңлекләрдә массакүләм кредитлау соңгы унбиш елларда гына кулланышка керде, шуңа күрә әҗәтләр масштабы буенча алга киткән илләрдән күпкә калышабыз. Кризиска бераз гына соңгарак калып керәбез. Процентлы кредит шундый механизм бит ул: башта үсеш темплары белән сөендерә, җимерелү һәм суган суы суыру аз гына соңгарак калып башлана. Моны Үзәк банкта яхшы аңлыйлар, шуңа күрә Нәбиуллина ханым, массакүләм өстенлекле ипотека кредитларын туктатырга кирәк, дип өзгәләнә. Хәзер ипотеканы туктатырга да соң инде, дәвам итү дә куркыныч. Туктатсаң, торак базарында бәяләр төшү һәм җимерелү бүген үк башланачак, дәвам итсәң, якын киләчәктә биектәнрәк егылырга туры киләчәк. Ике золымның кечерәген сайларгамы, зуррагынмы – бәхәс шул тирәдә бара. Үзәк банк кечерәк золымны сайлауны куәтли, хөкүмәт, үсеш темплары белән алданып, бәла масштабын үстерү ягын каера. Бәлки, киләчәктә шеш үзеннән-үзе суырылып бетәр әле, дигән иллюзияләр белән яши министрлар. Бурычлар күләме исә баш әйләндергеч темплар белән үсә. Россиялеләрнең банклар алдындагы гомуми бурычы 30 триллион сумнан ашып киткән. Бу федераль бюджетка караганда зуррак суммага әверелеп бара. Үзәк банк мәгълүматлары апрель аенда гына да бурычларның 527 миллиард сумга – тиңе булмаган күләмдә артуын күрсәтә. Икътисадый үсеш темпларын тотып торырга ярдәм итә бу сан, әмма: а) инфляция вәгъдә итә, ә) киләчәктә җимерелү гарантияли.

Кредитка мал туплау россиялеләрнең матди хәлен яхшыртмый, яхшыра дигән алдану гына бирә. Искә төшерик әле: үткән көздә доллар ничә сум иде? 60–65 сумнар тирәсе йөрде. Хәзер күпме? Минем компьютер, Арча банкларында долларны 83 сумга сатып алып була, ди. Менә шул шул. Статистика безгә чуклы-бизәкле саннар күрсәтә ул. Аның эше шул: юатып тору. Әмма саннарның чынбарлыкны шәйләргә булыша торганнары да бар. Иң мул тормышлы россиялеләр кайда яши әле? Мәскәүдә. Менә шул мәскәүлеләр соңгы вакытта үзләре яшәгән фатирларның бүлмәсен бик теләп арендага бирә башлаганнар. Шундый белдерүләр күләме 80 процентка арткан. Кеше үзе яшәгән фатирга фатирдашны акчага бик мохтаҗ булганда гына кертә. Уңайсызлыклары бик күп чөнки.

Россиянең матди ресурсларын көнбатыш чикләрдәге конфликт һәм санкцияләр бик нык суыра. Әмма дөнья кризисының кискенләшүе алардан да зуррак зыян салырга ихтимал. Без хәзер нәкъ шул чиктә басып торабыз.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

# ГОРУРЛЫК БӘЙРӘМЕ

**12 июнь – Россия көне уңаеннан Казанда берьюлы берничә мәйданда бәйрәм чаралары узды. Аларда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты.**

tatarstan.ru

«Россия – чын мәгънәсендә, яу кырында һәм тыныч тормышта һәрчак илебез мәнфәгатьләрен якларга әзер булган батырлар ватаны. Махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләрнең кыюлыгы, каһарманлыгы һәм фидакарьлеге – моның ачык дәлиле. Бүген, Россиянең суверенлыгы һәм киләчәге өчен көрәш барган шартларда, күпмилләтле халкыбыз, бердәм булып, заман сынауларына каршы тора. Безне уртак язмыш берләштерә һәм туган җиребездә барлык авырлыкларны да җиңеп чыгачакбыз. Безнең рухыбызны сындыра алмаслар!» – диелә Татарстан Рәисенең Россия көне уңаеннан мөрәҗәгатендә.

Башкаланың «Черек күл» паркында икеләтә бәйрәм кәефе хөкем сөрде. Биредә Россия көне һәм «Динамо» спорт җәмгыятенең 100 еллыгы уңаеннан тантаналы чара узды. Бәйрәм сәхнәсендә чыгыш ясаганда, Рөстәм Миңнеханов Россия көненең төп дәүләт бәйрәме булуын тагын бер кат ассызыклады.

– Без илебез, аның күпгасырлык тарихы, мәдәният һәм традицияләребезнең күптөрлелеге белән горурланабыз. Хәзер, Ватаныбызга моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә басым ясалган шартларда, бу бәйрәм тагын да зуррак әһәмияткә ия, – диде ул.

Ул билгеләп үткәнчә, Россия Президенты Владимир Путин билгеләгән юл ярдәмендә дәүләтнең хәрби-оборона мөмкинлекләре көннән-көн ныгый, икътисадның тотрыклылыгы саклана, җәмгыятебезнең берләшүе арта.

Илдәге тотрыклылык, милләтара һәм динара тынычлык, татулык турында Казан Кремлендә алдынгы татарстанлыларга дәүләт бүләкләре тапшыру тантанасында да сөйләштеләр. Чара Россия көнен бәйрәм итүгә багышланды. Традицион рәвештә бүләкләнүчеләр арасында республика һәм ил үсешенә зур өлеш керткән фән, сәламәтлек саклау, сәнәгать, төзелеш, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре бар иде.

– Сезнең хезмәтегез – үсеп килүче буын өчен иң яхшы үрнәк. Лаеклы бүләкләрегез белән котлыйм. Тагын бер тапкыр сайланган эшкә тугрылыгыгыз өчен рәхмәт. Сезнең казанышларыгыз – күпьеллык намуслы хезмәт нәтиҗәсе. Уңышларыгыз тарихы дәвам итәр дип ышанам, – дип чарада катнашучыларга ихлас теләкләрен җиткерде Рөстәм Миңнеханов.

Башкалада көне буе дәвам иткән бәйрәм чаралары салют белән тәмамланды.

## 23 ӨМЕТ

**Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Хөкүмәт йортында кадрлар резервының (ТРның идарәче кадрлары резервы) яңа составына керүчеләр белән очрашты. Ул республиканың киләчәге дип өмет итүчеләргә уңышлар теләде.**

Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, Татарстанда идарәче кадрларны сайлап алу һәм әзерләүгә зур әһәмият бирелә.

– Әлеге резерв сезгә үзегезне бары тик яхшы яктан гына күрсәтергә, остазларыгыздан кыйммәтле киңәшләр алырга һәм белем тупларга, шулай ук республика үсеше өчен үз идеяләрегезне тормышка ашырырга ярдәм итәчәк дип ышанам, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Билгеле булганча, кадрлар резервы республикада ун елдан бирле төзелә. Быел барлыгы 266 кеше бу эштә катнашу теләген белдергән. «Алар арасыннан 23 кешене сайлап алдык», – дип сөйләде чарада Татарстан Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты җитәкчесе Александр Белов. Аның әйтүенчә, кадрлар резервына керүчеләр махсус укулардан тыш, республиканың дәүләт, муниципаль органнарында һәм оешмаларында да эшләп караячак. Шул исәптән министрлар һәм район башлыклары да тәҗрибә уртаклашачак дип көтелә.

## ЗАМАНАСЫНА КҮРӘ САК

**Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Цифрлы үсешкә теләктәшлек итү ассоциациясе утырышында катнашты. Чарада күтәрелгән төп мәсьәлә – республикада кибер куркынычсызлыкны тәэмин итү һәм әлеге тармак өчен белгечләр әзерләү.**

– Татарстан бу өлкәгә үзеннән саллы өлеш кертү һәм бик тә әһәмиятле булып саналган мәсьәләне хәл итү өчен барлык мөмкинлекләргә ия. Республикадагы 21 вузда (11 төп оешма һәм 10 филиал) компьютер һәм мәгълүмати белем бирү юнәлешләре буенча 12 меңгә якын кеше укый. Соңгы биш елда әлеге юнәлешне сайлаучы студентлар саны 40 процентка арткан, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Аның әйтүенчә, республикада IT белгечләр әзерләүче өч югары уку йорты әйдәп баручы инженер мәктәпләре оештыру өчен махсус мәйданчыклар булып тора. Биредә югары технологияле предприятиеләргә заманча инженерлык һәм тикшеренү компетенцияләре булдыру юнәлешендә эш башланган инде.

Рөстәм Миңнеханов тотрыклы цифрлы үсешне тәэмин итү өчен әле шактый эш башкарырга кирәклеген дә ассызыклады. Шул исәптән, дәүләт хакимияте органнарында һәм барлык предприятиеләрдә мәгълүмати куркынычсызлык өлкәсендә белгечләрне билгеләргә, бу юнәлештә эшләүчеләрнең белемен арттырырга кирәк, диделәр чарада.

Сүзне эш белән дәлилләп, Иннополис университеты Innostage компаниясе белән мәгълүмати куркынычсызлык өлкәсендә өйрәтү курслары төзүгә бәйле килешү дә имзалады. Тәүге онлайн курс быел чыгарга тиеш. Аның ярдәмендә хакер һөҗүмнәрен тизрәк танырга мөмкин булачак дип фаразлана.

## *Бакчага юрган ябасыммы?*

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Синоптиклар исә, алга таба мондый суыклар булмаячак, ди.

– Аномаль суытып җибәрүнең сәбәбе: без төньяктагы диңгезләрдән искән салкын җилләр агымына эләктек. Тик бу – гайре табигый хәл түгел. Һава агымнары гел үзгәреп тора. Инде бүген үк салкын җил урынына көньяктан җылы җил исә башлады. Шуңа күрә дә алга таба җылытачак, бигрәк тә төнлә һава температурасы күтәреләчәк, – ди КФУның метеорология кафедрасы доценты Тимур Әүхәдиев. – Тәүлек дәвамында һава температурасының кискен үзгәрүенә болытлар булмау да сәбәпче. Игътибар итсәгез, кичкә таба күк йөзе аяза. Ә болытлар җирдән күтәрелгән җылыны кире борып җибәреп, аны саклау ролен үти. Күк йөзе аяз булгач, җир өслеге тиз суына. Бу юлы да шулай булды, нәтиҗәдә һава температурасы 0 градуска кадәр төште. Моны бигрәк тә түбән урнашкан урыннарда яшәүчеләр тойды. Чөнки һава температурасы салкынрак булган саен, ул тыгызрак була һәм иңкүлекләргә төшә. Шул ук вакытта, июньнең беренче ун көне чагыштырмача салкын булды дип әйтә алмыйм. Бу чор өчен уртача һава температурасы 16,7 градус тәшкил итсә, быел ул – 16,2 градус. Тулаем июнь аена һава торышына килгәндә, ул уртача күрсәткечләрдән югарырак булачак дип көтелә. Алдан алынган фаразларга караганда, быел безне гадәттәгедән эссерәк җәй көтәргә дә мөмкин. Тик безне күбрәк явым-төшемнәрнең аз булуы борчый. Июнь башыннан бирле явым-төшемнәр 7 миллиметр гына теркәлде. Норма буенча исә әлеге күрсәткеч 60 миллиметр тәшкил итә. Ни кызганыч, быел яңгырлар безне читләтеп уза. Яуган кадәресе дә республика буенча бертигез дәрәҗәдә түгел. Казанда, мәсәлән, май аенда җитәрлек күләмдә явым-төшем теркәлсә, Татарстанның көнчыгышында яңгырлар, гомумән дә, яумады диярлек. Шунысын да әйтик: явым-төшемнәрне алдан фаразлап булмый.

Эльвира ВӘЛИЕВА

## Тынгысыз җәй

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Владимир Иванов сүзләренә караганда, соңгы арада балалар мәйданчыгына уйнарга чыккан җиреннән имгәнгән балалар саны да арткан. Аларның күбесе бирeдәге тау, баскыч кебек җайланмалардан егылып төшеп зыян күрә икән.

– Ата-ана баласын уен мәйданчыгына алып чыга да тынычлана. Күбесе башын да күтәрмичә телефонда утыра яки шундагы ата-аналар белән гәп кора. Ә бала бу вакытта бернинди караусыз теләсә кая менә, сикерә, җаны ни тели – шуны эшли. Моның ахыры еш кына имгәнү-җәрәхәтләр белән тәмамлана. Шуңа күрә ата-ана бу очракта да уяулыкны югалтмасын иде, – ди белгеч.

Уяулык дигәннән, табиблар табигатьтә ял иткәндә, бигрәк тә шашлык пешергәндә уяу булырга өнди. Ник дигәндә, андый чакта балаларның пешү куркынычы бермә-бер арта, дип кисәтә алар. Балаларның күбесе учак кабызганда кулланыла торган сыекчаны сибеп уйнаганда зыян күрә икән. Бәхеткә, соңгы араларда республикада андый очраклар күзәтелмәгән. Шулай да ел башыннан бирле Татарстанда 8 бала пешкән. Аларның тәненең 30 проценты зыян күргән. Күбесе өстенә кайнар чәй түгү, кайнар чәйнек аудару аркасында пешкән.

# БЕР ТАВЫШ ХӘЛ ИТӘ

**«Безнең ишегалды» программасы**

**Татарстанда 2024 елда төзекләндереләчәк парк-скверлар һәм ишегаллары өчен Бөтенроссия онлайн тавыш бирүдә 363258 кеше катнашкан. Бу узган елгыдан 75 процентка күбрәк. Тавыш бирү өчен республиканың 267 объекты тәкъдим ителгән иде. Бу хакта Министрлар Кабинетында «Татарстанда төзекләндерү объектларын сайлап алу буенча Бөтенроссия онлайн тавыш бирү йомгаклары»на багышланган брифингта сөйләделәр.**

kzn.ru

«Безнең ишегалды» программасына кертеләсе ишегаллары ничек сайлап алына соң? Аларның төзекләндерүгә мохтаҗ булганнарын башта исемлеккә кертәләр, аннан соң иң беренче чиратта яңартыласыларын тавыш биреп сайлыйлар. Исегезгә төшерәбез: Дәүләт хезмәтләре порталы шәхси битендәге «Татарстанда яшәүчеләр өчен сораштыру» дигән бүлектә ишегаллары өчен һәркем тавыш бирә алды. Биредә һәркем үзе яшәгән территориядәге ял урыннарын сайлап, төзекләндерергә кирәк дип уйлаган урыннарны үзе дә тәкъдим итә ала иде. Тавыш бирү 15 майдан 30 майга кадәр дәвам итте.

Төзекләндерүгә керешкәнче халык белән шактый фикер алышалар. «Безнең ишегалды» программасын оештыручылар яңартылачак урыннарга чыгып, анда яшәүчеләр белән очраша. Әлбәттә, кеше күп җыелган җирдә фикер дә күп, каршылыклар да килеп чыга. Әмма программаны тормышка ашыручылар да ничек тә алтын урталыкны таба белә. Бөтен кешенең фикеренә колак салып эшлиләр.

**САН**

Татарстанда 2020–2022 елларда «Безнең ишегалды» программасы кысасында 3379 ишегалдында 25 млрд сумлык төзекләндерү эшләре башкарылган. 2023 елда 9 млрд сумга 961 ишегалды яңартылачак.

«Безнең ишегалды» программасы кураторы Арина Петрова сүзләренчә, алга таба да халык белән очрашулар дәвам итәчәк. Әмма быелдан аның яңа форматын тапмакчылар.

– Без киләчәктә халык белән очрашуларны мобиль кушымта аша үткәрмәкче булабыз. Кайвакыт эшләрне планлаштырганда мондый формат та кирәк. Күрешеп очрашуны берни алыштыра алмаса да, онлайн бер зур күрешү кирәк дип саныйбыз. Шул рәвешле без яшьләрне дә бу темага җәлеп итмәкче булабыз. Алар җыелышларга йөрми, ә менә мобиль кушымта аша кушылырлар иде. Аларның фикерләрен дә беләсебез килә, – ди Арина Петрова.

Куратор быел ишегалдындагы эшләрнең кызурак баруын да әйтте.

– Быел яз иртә килү сәбәпле, эшләр бер ай алдан башланды. Инде планлаштырылган юл эшләренең 41 проценты тәгәлләнеп килә. Узган ел без бу вакытта эшләрнең бары 33 процентын башкарган идек. Тиз эшләнү сөендерә, – ди ул.

Тавыш бирүдә җиңеп, «иң-иң»нәр исемлегенә кергән 200 ишегалдының 67се Казанда урнашкан. Вахитов һәм Идел буе районнарында яшәүчеләр аеруча актив булган.

Яшел Үзән районы башлыгы Михаил Афанасьев үз районнарында башкарылган эшләр турында сөйләде. Быел Яшел Үзән районында 76 ишегалды төзекләндереләсе икән. Идел яр буйларын матурлау планы да бар. Киләсе елларда Норлат авылында да «Безнең ишегалды» программасы ярдәме белән төзекләндерү эшләре башкарылачак.

Район башлыклары дигәннән, бер очрашуда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов аларны нәкъ менә шушы программа буенча әкрен эшләүләре өчен тәнкыйтьли. Кайбер районнар җитәкчеләренә кисәтү дә ясый. Рәис сүзенә колак салганнармы? Арина Петрова әйтүенчә, алар һәр район җитәкчелеге белән аңлашып, уртак фикергә килеп эшли. «Кемнедер аерып күрсәтәсе килми. Әлбәттә, арттарак калучылар да бар. Әмма бергәләп тотынгач, аларның да мөнәсәбәтләре үзгәрә», – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов Казанның «Салават Күпере» торак комплексындагы паркны ошатып кайткан. Анда эт тотучылар өчен аерым бер мәйданчык булдырылган. Татарстан Рәисе йорт хайваннарына җаваплы карарга кирәклеген искә төшереп, мондый тәҗрибәне башка парк-ишегалларында да кулланырга кушкан. Бүген республикада этләрне йөртү өчен 17 махсуслашкан урын бар икән. Киләчәктә аларның санын арттырмакчылар. Бу урыннар хуҗалы этләр өчен генә.

**«Безнең ишегалды» программасы кысасында башкарылырга тиешле эшләр:**

- юл, тротуарлар төзекләндерү;
- эскәмияләр урнаштыру;
- чүп савытларын яңарту;
- ут баганаларын төзекләндерү яки яңаларын кую;
- балалар өчен уен һәм спорт җиһазларын урнаштыру;
- каты көнкүреш калдыклары өчен мәйданчыклар булдыру яки яңарту.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

# ИРЛӘРЧӘ СӨЙЛӘШҮ

Ватан хакына

**Ничек кирәк, шулай ярдәм итәрбез! Район башлыкларының махсус хәрби операция зонасыннан ялга кайткан егетләр белән очрашуларында иң еш яңгыраган сүзләр бу. Хәрбиләрне һәм аларның якыннарын нәрсә борчый? Кәефләре ничек? Без әнә шуларны белештек.**

Күп кенә районнарда ялга кайткан егетләр белән очрашу чәй табыны янында узган. Шул арада район башлыклары аларның хәлләрен белешеп, өйдә сагынып көтүче якыннарына һәм хәрбиләрнең үзләренә каралган ярдәм чаралары турында сөйләгән.

**Яңа Чишмә** районы егетләре, мондый ярдәм булганда, тылдагылар өчен тыныч без дип, райондашларына рәхмәт сүзләрен җиткергән. Район башлыгы Вячеслав Козлов белән очрашуда хатыны Юлия белән ялга кайткан Алексей да катнашкан. Әле күптән түгел генә уллары туган бу гаиләгә бала арбасы алу өчен сертификат тапшырганнар.

– Башта җиңел булмады, азык-төлек, су, сугыш кирәк-яраргы җитми иде. Аннары барысы да җайланды. Барлык кирәкле әйберләрне якташларыбыз ярдәме белән тупладык. Минем әти генә дә тугыз мәртәбә безнең частька техникага запас частьлар һәм башка бик күп кирәкле әйберләр алып килде, – дип уртаклашкан капитан Евгений.

Бераз ял итүгә янә иптәшләребез янына китәбез, ди хәрбиләр. Берничә көнгә генә кайтсалар да, районның 10 нчы сыйныф егетләре өчен оештырылган хәрби лагерьга да барып килергә өлгергән алар. Чын мәгънәсендә тәҗрибәле егетләр мәктәп укучыларына белгәннәрен өйрәткән, аларга гадәттән тыш хәлләргә әзер булу өчен нинди күнекмәләр алырга кирәклеген аңлаткан.

Мондый очрашулар **Түбән Кама** районында да еш уза. Район башлыгы Рамил Муллин, ялга кайткан егетләрне даими рәвештә чәй өстәле янындагы очрашуга чакырып, аларның зар-теләкләрен тыңлый. Шундый очрашуларның чираттагысы 6 июньдә узган.

– Хәрбиләребез күбесенчә якыннарын кайгырта. Әйтик, 6 июньдә узган дүртенче очрашуда балаларын логопед белән шөгыльләнә торган махсус тәрҗемгә күчерүләрен сорап мөрәҗәгать итүчеләр булды. Ә болай, үзләрендә бөтен нәрсә бар, ди инде алар. Зарланып утыручы булмады. Ашау ягы да яхшы, диләр. Билгеле, техника мәсьәләсендәге җитешсезлекләр турында да әйтеп уздылар, ләкин район кулыннан килгәнчә ярдәм итә. Безнең вәкаләттә булмаган нәрсәләр дә бар бит, – дип сөйләде «ВТ» хәбәрчесенә район башкарма комитетының мобилизацион әзерлек һәм халык иминлеге бүлеге башлыгы Раил Габидуллин.

**Кайбыч** районы башлыгы Альберт Рәхмәтуллин белән дә хәбәрләштек. Махсус хәрби операция зонасыннан ялга кайткан егетләр белән ике атна саен диярлек күрешеп тора алар. Чираттагы очрашу киләсе атнада булачак икән.

– Чәй өстәле янында иптәшләрчә, матур гына сөйләшәбез. Сүзләрен кыска тоталар. Егетләрчә, барысы да әйбәт, дип чикләнәләр. Беренче мәлләрдә төрле хәлләр булды, хәзер инде ияләштек, диләр. Кәефләре

arskmedia.ru

**Хәрби операция зонасыннан ялга кайткан егетләр арасында гаилә корып калырга ашыгучылар да бар. Әйтик, Арча районының Субаш Аты авылы егете Рифат ялга кайткан арада сөйгәне Ләйсән белән өйләнешкән. «Арча хәбәрләре» язуынча, махсус хәрби операция зонасында алгы сафларда хезмәт иткән егет сөйгәненә, ялга кайту белән, языльшабыз, дип вәгъдә биргән. Һәм вәгъдәсен үтәгән. Яшь гаиләгә алтын туйларын да бергә каршылауларын телик!**

бик яхшы. Ялга кайткан җирдән кире китәсе килми, диючеләр юк. Анда безне дусларыбыз, иптәшләребез көтә, аларның да ялга кайтасылары бар, дип кенә торалар. Гаиләләре өчен борчыласы юк: район буенча һәр гаиләгә бер кеше билгеләнгән. Проблемалар була калса, бергәләп хәл итәбез, – дип сөйләде Альберт Рәхмәтуллин.

**Мамадышта** исә махсус хәрби операциядә катнашучы егетләрнең әниләрен очраштырганнар. Район башлыгы Анатолий Иванов сүзләренчә, район хакимияте батыр егетләрнең әти-әниләренә һәм туганнарына ярдәм итәргә һәрвакыт әзер.

– Сез – чын мәгънәсендә кыю һәм намуслы геройлар үстергән аналар. Районыбызда яшәүче һәр кеше исеменнән әйтәм: без сезнең батыр улларыгыз белән чын күңелдән горурланабыз һәм исән-имин кайтуларын телибез. Нинди генә ярдәм кирәк булса да, район хакимияте сезнең үтенечне тыңларга һәрвакыт әзер, – дип мөрәҗәгать иткән ул аларга.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

# Болгарга кайту

Сәләт-2023

**Бирегә әйләнеп кайтуны монда ял иткән һәр сәлкеш, әйдаман бик көтте. Һәм, ниһаять, сәләтлеләр – Болгарда! X Төбәкара «Болгар – Туган тел» аланына Татарстаннан һәм илнең 11 төбәгеннән 400 бала җыелды.**

«Болгар – Туган тел» аланы инде 10 ел дәвамында сәләтле балаларны берләштерә. Төбәкара форум исә 2019 елдан бирле Биләрдә үткәрелә торган булса, быел тарихи Ватанына, янәдән Изге Болгар җиренә кайтты! Бирегә ул 12–18 июньдә узачак. Форумның ачылышында без дә булдык.

Алан программасы татар телен, мәдәниятен өйрәнүгә, телнең төрле өлкәләрдә кулланылышын арттыруга юнәлтелгән. Ул бер-берсен тулыландыра торган төрле тематик өлешләргә бүленгән мәдәни һәм белем бирү чараларыннан тора. Үз эченә тарих, татар, инглиз теле, риторика, актерлык осталыгы һәм тагын бик күп үзенчәлекле остаханәләр һәм дәресләрне ала.

Ачылу тантанасында сәлкешләрне һәм әйдаманнарны Татарстан Рәисе ярдәмчесе, «Алдынгылар хәрәкәте»нең республикадагы бүлеге җитәкчесе Тимур Сөләйманов сәламләде.

– Сез – көч, сез – дәрт, сез – алгарыш, энергия! Монда Татарстаннан тыш, 11 төбәктән сәләтле балалар җыелды. Без бердәм, без көчле! – диде Тимур Сөләйманов. – Бер-берегез белән танышыгыз, укыгыз, рәхәтләнеп ял итегез. Форумның иң зур яме – сез үзегез. «Сәләт»ле җәйне башлап җибәрәбез. Мин үзем дә Болгар, Биләр җирендә, «Сәләт» белән бергә үстем. Мондагы мохит, монда булган хисләр, энергия мине әле дә тормышымда әйдәп бара.

Сәлкешләр белән дә аралашып алырга җай чыкты. Башкортстанның Уфа шәһәреннән килгән 17 яшьлек Илдан Кәлимуллинның «Сәләт» дөньясы белән танышуының тәүге көннәре икән.

– «Болгар – Туган тел» турында җиденче сыйныфта укыганда белдем. Дусларымның да монда булганы бар иде. Алар миңа бу алан турында бик күп сөйләделәр һәм ул миңа шундук ошады. Ул мохитне үз күзләрем белән күрү, тою өчен мин үзем барырга булдым. Әле монда бер генә көн булсак та, мин инде бик күп дуслар таптым. Чатырларда яшәү дә ошый. Татарстан лагерьларында булганым бар иде. Әйтергә кирәк, аларга караганда, «Сәләт»тә үзгә, җылы атмосфера. Мин – иҗади шәхес. Безнең шәһәрдә, республикада татар телендә узган чараларда, олимпиадаларда, шигырь конкурсларында катнашам. Шуңа күрә дә «Болгар – Туган тел» аланы миңа якын. Мин монда татар телемне тагын да камилләштерәм, – диде Илдан.

Ләйсән САФИНА

selet.biz

Хушлашу

# АНДЫЙ КЕШЕ БАШКА БУЛМАС ИНДЕ

**Сәнгать дөньясында тыныч кына, сабыр гына тагын бер йолдыз сүнде. Ул оста баянчы, талантлы музыкант, Татарстанның халык артисты Рәшит Мостафин иде.**

Бәхетебезгә, соңгы эш урыныбыз Тукай урамы почмагында Рәшит белән янәшә булды. Маэмаен йөртергә чыкканда, гел очраша, сөйләшә, күп әйбердән хәбәрдар идек.

Авыр хәбәрне ишетү белән йөгереп килдем. Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани урамнарында халык бик күп иде. Мәчеттә җеназа укыр алдыннан мулла бабай халыктан: «Нинди кеше иде, бурычлары калмадымы?» – дип сорады. Аны яхшы белүчеләр, бертавыштан: «Бик яхшы, тыйнак, акыллы, сабыр, матур кеше иде», – дип пышылдадылар.

Әйе, бу шулай. Рәшит шундый кеше иде. Дөньялыкта бөтен эшен төгәлләп, яхшы эшләр, тәртипле, сәнгатькәр балалар калдырып, Балтачка, әнисе янына Саснага кайтып китте. Аллаһ аңа хәерлесен бирсен. Якты нуры озак еллар килеп торыр әле. Шулай да бик моңсу, андыйлар булмас инде.

Шулай дип язып куйдым да туктап калдым, шундый кеше буламыни, диярләр. Әйе, була, бар: ул – Рәшит Мостафин. Кирәк чакта хәтта моң чишмәләребез Илһам Шакиров, Әлфия Авзалованың да көен көйләп җибәрә. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблен үзара «цех»ларга бүлеп йөртәләр: җырчылар, биючеләр, музыкантлар. Әнә шул музыкантларның – оркестрның җитәкчесе, Татарстанның халык артисты Рәшит Мостафин – җырчыларга да, биючеләргә дә җан өрүче, хәрәкәткә китерүче, тамашачы, тыңлаучы, халык белән тоташтыручы.

Катлаулы язмыш иясе Рәшит Мостафин, гомеренең бер чорында очучы да була – зәңгәр күктә самолетка ут капкач та исән кала алган, СССРның һәм Европаның барлык елгаларын колач салып йөзгән егет. Аннары кулына гармун тотып дөнья иңли.

Күңелемнән аның белән очрашуларны искә төшерәм.

...Менә сәгатьтән артык инде аны көтеп утырам. Ул исә бу юлы да очрашуга вакытында килмәде. Әй, Рәшит, Рәшит, дим, сиңа да 50 тула икән бит инде. Андый чакта синең кебекләр редакцияләрдән китеп тормыйлар, мәкалә яздыралар, фотоларын китерәләр. Синең бәйрәмеңне белми дә калган булыр идек әле, ярый, чакыру китергәнсең. Рәхмәт инде. Менә шуның өчен дә, юк, аның өчен генә түгел, татар халкының бик кадерле, зурлауга, олылауга, хөрмәтләүгә лаек музыканты булганың өчен синең хакта күп итеп, матур, җылы итеп язу һич артык түгел.

Моннан берничә ел элек тә очрашуга ул биш минутка соңарып килде, зур гөнаһлы кешедәй, гафу үтенергә тотынды. Аннан соң үзе дә көлеп җибәрде: «Әни өйдә юк иде, – диде. – Концертка, очрашуга барасы булса, миннән уздырып, ул әзерләнергә тотына. Янәсе, соңга кала күрмә. Әгәр инде атна арасында ял туры килеп, көне буе өйдә торсаң, әнигә ошамый. Үзенең иң изге саналган сүзләрен мең дә беренче тапкыр кабатларга тотына: «Мин кырык ел буе бер заводта эшләдем, гомеремдә бер генә мәртәбә дә прогул ясаганым булмады». Күпсанлы грамоталары, медальләре, рәхмәт язулары бар. Пенсиягә чыкканына егерме елдан артса да, бәйрәм саен заводларыннан котлаулар килеп тора. Сабыр, тыйнак ул минем әни».

Инде үзе ир уртасы булып өлгергән кешенең дулкын-дулкын чәчләре, әгәр кара булса, күптән инде агарыр иде. Ярый әле, арыш көлтәседәй сары булган. Әни, әни, дип сөйләп утыруы да шундый килешә. Әтисен ул хә-

терләми, «кара машина» аны төнлә, улына – бердәнбер баласына җиде ай булган көнне алып киткән. Шулай да Рәшит аны яхшы хәтерли дә, күргән дә кебек. Әтисе турында әнисе төннәр буе сөйли-сөйли дә елый. Күрәсең, аның турында көндез сөйләргә ярамый. Бик яхшы кеше булган ул һәм бик оста гармунчы. «Син дә шулай булырга тиеш...»

Казан шәһәрендәге Такташ урамыннан шук-шаян, усал малаен ялгыз анага гармунчы итү өчен, ай-һай... Ярый әле, Бәдернисаның туган яклары – Балтач районының Сасна, Чапшар авыллары бар. Әнисе улын тыңлата алмаса, шунда кайтарып куя. Ә бер кайтуда Рәшит шофер Гарәфи абыйга гашыйк булып килә. Өйгә кайткач, аның ничек гармунда уйнавын, ничек машина йөртүен, күргәннәрен сөйләп туя алмый.

Музыка мәктәбенә килгәч, аларны Миңҗамал Мазунова каршы ала. Рәшит өчен бер дә тырышлыгын җәлләми. Малайның күңелендә, җанында күренмәгән моң бар. Ул шуны күреп ала. Әнисен дә соңгы акчасына яшел гармун сатып алырга күндерә. Ә беркөнне Бәдерниса апа матур тавышлы гармунның идәндә таралып ятканын күреп егылып китә яза. Улы исә, гармун ясыйм, ди. Әни бул да шул чакта ачуланмый, тавышыңны күтәрми түзеп кара әле. Бәдерниса агыннан, карасыннан бер сүз дәшми. Бер атнадан Рәшит гармунын күтәреп, эштән кайткан әнисен каршы алырга чыга.

– Ишетәсеңме, тавышы ничек матурланды, – ди.

Музыка мәктәбендә аны мактап, күршеләр тыңлап туя алмыйлар. Ә менә музыка училищесында бер ел укыгач, Рәшит Мостафинны куып чыгаралар. Имеш, музыка аның кебекләр өчен түгел. Канатлар каерыла. Андый чакта малайларга әти кирәк. Аны әни алыштыра. Бара Бәдерниса апа, күз яшьләрен эчкә йотып, урамда узганда сәлам дә бирмәслек кешеләргә тезләнә. Сүзе үтми. Кыңгыр эш кырык елдан соң фаш була: ул елларда училищеда Герасимов классына татар малайларын алмаганнар икән. Рәшит тә ялгыш кына эләккән булган.

Бу – Һади Такташ урамының, Кабан күле буйларының иң бәхетле еллары. Вахитов клубы, күл буйлары җыр-биюдән гөрләп тора. Бергә бокс «сугыш»ына киләләр, бергә көрәшкә йөриләр, бергәләшеп концертлар куялар. Яшьтәшләренең күбесе очучы, хәрби кеше булып китә. Сигезе профессиональ сәнгатькә аяк баса, халыкка хезмәт итә.

Бәдерниса апа, Рәшитне җитәкләп, Ижауга китә. Малаен уйнатып карыйлар да, өйрәнергә кыйммәтле баяның булса, алабыз, диләр.

– Бар, – ди Бәдерниса апа, күзләрен дә йоммыйча. Кеше ялганлаганын да кичерә алмаган әнисенә карап, Рәшит авызын ябарга онытып тора. Әнисе исә аның саен: «Бар, бар, аның 800 сумлык ап-ак зур баяны бар», – ди. Үзе исә өйгә кайткач, көне буе туганнарны, дус-ишләрне, сер сыяр кешеләрне йөреп чыга, бурычка акча җыя. Улы хыялланырга да курыккан баянны сатып алып бирә дә укырга озатып кала.

– Менә шуннан соң укымыйча кара инде, – ди Рәшит. – Шундый ул минем әни!

Укучым Рәшитнең баянчы, вак гармуннарда уйнаучы, аларны үзе дә төзәтүче, ясаучы Мостафин булуын аңлагандыр инде. Аны халкыбыз белә, ярата, телевизорлардан сокланып тыңлый. Концертына теләп йөри. Илебезнең Воронеж, Мәскәү, Ленинград кебек шәһәрләрендә Бөтенроссия дипломанты булуын да яхшы хәтерли.

Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблен Япония алкышлады. Тамашачылар Мостафинның гармуннарын күргәч, исләре киткән. Токионың аккордеончылар ассоциациясе аны кунакка чакырган, туйганчы уйнатканнар һәм бик матур, зур, кыйммәтле, ялт-йолт итеп торган аккордеон бүләк иткәннәр. Дөрес, Рәшит тә бурычлы булып калмаган. Иң кечкенә, иң матур тавышлы гармунын ул аларга калдырган.

Кечкенә гармун дигәннән, Рәшитнең Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә эшләп йөргән чагы була. Авыр сулап, нишләргә белмичә өйгә кайтып керә.

– Әни, – ди ул, өзгәләнеп, – бир әле бер киңәш. Нишлим, кайдан алыйм икән, бик күп акча кирәк миңа, – ди.

– Мотоциклыңны сат, – ди Бәдерниса апа, бер дә уйлап тормыйча.

Туйганчы йөрергә дә өлгермәгән мотоциклны Рәшит көне-сәгате белән сата да кесә тулы акча ясый. Ә кич белән мәрхүм Фәйзи ага Биккининнның сигез гармуны – татар сәнгатенең үткәне һәм киләчәге Рәшит Мостафиннар өенә күчә. Һәм бүген дә халыкка хезмәт итә. Югыйсә алар күп акчалы берәүнең затлы шкафына күчеп утырырга да бик мөмкин иде.

Моннан соң да әле Рәшит Мостафин турында күп яздым. Яратып, сокланып яздым. Нәкъ менә ул, аның кебекләр халкыбызның йөзек кашы, намус сафлыгы, йөз аклыгы булган Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблен саклап калды. Соңгы елларда Рәшитнең кызы – биюче Ләйсәннең ире Айрат Хәмитовның ансамбльгә җитәкче булуы да отышлы булды. Бер кинода, композиторы – Искәндәр Мостафин, дигәч тә сөендем әле. Улмы икән, юкмы икән, никтер ул миңа Рәшитнең улыдыр кебек тоелды. Аның да җырга-моңга гашыйк икәнен белә идем. Рәшит оныкларына, яшь хатыныннан туган балаларына татар моңнарын өйрәтә.

Үзе Мәккәгә барып кайтты, хаҗи булды. Урамда, берәр концерт-мазарда очрашсаң, сөйләшеп сүз бетми. Озакламый әнисенә дә 100 яшь тула инде. Яз да яз иде дә соң...

Фәния ХУҖАХМӘТ

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе **Җәббаров** Азат Галимҗан улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Яшь буынга хәрби-патриотик тәрбия бирүгә һәм югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә мөһим өлеш кертүе өчен Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Казанның Жуков орденлы Кызыл байраклы югары танк команда училищесы» федераль дәүләт казна югары хәрби белем бирү мәгариф учреждениесе башлыгы урынбасары, полковник **Урин** Александр Николаевич **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Яшь буынга белем һәм хәрби-патриотик тәрбия бирүгә лаеклы өлеш кертүләре өчен Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Казанның Жуков орденлы Кызыл байраклы югары танк команда училищесы» федераль дәүләт казна югары хәрби белем бирү мәгариф учреждениесе хезмәткәрләре: училище башлыгының тыл буенча урынбасары – матди тәэминат бүлеге башлыгы, полковник **Новосельцев** Владимир Алексеевич, уку-укыту процессын тәэмин итү батальоны командирының корал буенча урынбасары, майор **Суслин** Илдар Наил улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм 1941–1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүгә зур өлеш кертүе өчен Бөек Ватан сугышында катнашучы **Әһлиев** Зәйнәк Әһли улы; Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Владимирова** Алевтина Геннадьевна, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы рәисе **Кәримов** Миргасыйм Ильяс улы; конфессияләр арасында татулыкны һәм тынычлыкны ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте үзәкләштерелгән дини оешмасының Югары Ослан мөхтәсибәте Кызыл Байрак авылының Йосыпов исемендәге мәчете мәхәлләсе җирле мөселман дини оешмасы имам-хатыйбы **Ибраһимов** Тимур Яхъя улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

# КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе, галим, педагог, дәүләт хезмәте ветераны

**ФОКИН Аркадий Васильевич**

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Ул 1990 нчы елларда, илдә демократик үзгәртеп корулар башланган бер мәлдә, милләтара тынычлык һәм татулыкка зур игътибар биреп, Татарстанның милли-мәдәни тормышына актив төстә җәлеп ителде. Үз гомеренең бик күп елларын керәшеннәрнең мәдәни һәм тарихи мирасын, традицияләрен өйрәнүгә багышлады. 1994–2003 еллар чорында Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының җәмәгатьчелек һәм милләтара мөнәсәбәтләр бүлеге милләтара мөнәсәбәтләр секторына җитәкчелек итте. Үз эшенең остасы, көч-дәрте ташып торган оештыручы һәм зирәк остаз булды.

Фокин Аркадий Васильевичның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

## КАЙСЫ РАЙОНДА КЕМ БАТЫР КАЛДЫ?

**«ВТ» район үзәкләрендә узган Сабантуйларда батыр калган егетләрнең исемлеген барлады.**

Азнакай – **Альберт Мамалимов**
Актаныш – **Азат Габдрәшитов**
Аксубай – **Айрат Хәлиуллин**
Алабуга – **Илнар Галимов**
Алексеевск – **Олег Курнашов**
Апас – **Рафаэль Хәсәнов**
Арча – **Альберт Ситдыйков**
Әгерҗе – **Тимур Кәримов**
Әлки – **Алмаз Хәмидуллин**
Әлмәт – **Айдар Алтынбаев**
Әтнә – **Ирек Мөхәммәтшин**
Балтач – **Руслан Рәфыйков**
Балык Бистәсе – **Илмир Төхвәтуллин**
Баулы – **Илшат Юсупов**
Биектау – **Азат Яруллин**
Буа – **Марат Миначев**
Бөгелмә – **Алексей Захаров**
Зәй – **Рамил Фаршатов**
Кайбыч – **Раил Фәсхетдинов**
Кама Тамагы – **Лениз Абдуллин**
Кукмара – **Ринат Дәүләтшин**
Лаеш – **Муса Галләмов**
Лениногорск – **Рөстәм Юсупов**
Мамадыш – **Эльмир Ахунҗанов**
Менделеевск – **Ранис Гыйлаҗетдинов**
Минзәлә – **Илнур Камалов**
Мөслим – **Илнар Сәетгалиев**
Нурлат – **Марсель Гозәеров**
Питрәч – **Азат Яруллин**
Саба – **Дилүс Закиров**
Сарман – **Алмаз Вахитов**
Спас – **Ришат Сәгыйров**
Тәтеш – **Илназ Шәмсетдинов**
Теләче – **Раил Нургалиев**
Тукай – **Илназ Рамазанов**
Чирмешән – **Рәсим Шириев**
Чистай – **Айнур Сыртаев**
Чүпрәле – **Раил Камалов**
Югары Ослан – **Ришат Җаббаров**
Ютазы – **Хәмит Миңнуллин**
Яңа Чишмә – **Илсур Сафин**
Яшел Үзән – **Айдар Әхмәтов**

**Мамадыш**

Яңгыр да комачау итми. Сабантуйга бүләк җыям дигән кешегә берни киртә түгел икән. Мамадышта узган бәйрәмнән соң әнә шундый фикергә киләсең. «Боз түгел, эремәбез әле», – дип биюче дә, капчыкта йөгерүче дә, кул көрәштерүче дә, салкын суга чумып балык тотучылар да, хәтта ярышып өчпочмак ашаучылар да бар иде.

Соңгысы бөтенләй шаккатырды. Бер көтү халык ярышып өчпочмак ашады. Билгеләнгән вакытка кем күбрәк ашый, шул – җиңүче. Ризыкны йотып җибәрер өчен Мамадыш лимонады да салып бирәләр. Кемдер икене ашый, кемдер бишне. Ә менә кунак егет Рөстәм, 10 өчпочмак ашап, җиңүче булды. Тамак та тук, 3 мең сум акча да – кесәдә.

Рөстәмне, Татарстанның атказанган җырчысы Иркә күреп, сәхнәгә чакырды. «Берәр өчпочмагыңны миңа да калдырмагансың», – дип шаяртып та алды. Аның каравы тәмлетамак Рөстәмнең ике битеннән үбеп котлады. Ишеп яңгыр яуса да, тамашачы Иркәнең җырлавын тыңлады. Берәү дә кайтырга ашыкмады. Мәйданның һәр почмагы гөрләп торды. Бер якта көрәшчеләр ут чыгарса, икенче якта «Татар кызы» бәйгесе узды.

Әмма Сабантуйда күңелгә иң ошаганы һәр милләтнең үз гореф-гадәтен күрсәтеп, үз ризыгы белән сыйлап җибәргән почмак булгандыр. Бу урын бөтен кешенең күңеленә хуш килде дисәм дә, арттыру булмас.

Мамадышка кунак булып кайткан Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов та һәр милләт кешесенең күңелен күрде. Чуашча да, марича да биеде. Керәшеннәрне, удмуртлар, русларны да урап узмады, татарлар белән дә җырлап күңел ачты. «ВТ» журналистына бәйрәмне бик ошатуын да әйтте ул. «Мамадышта тырыш, уңган, булган халык яши», – дип тә өстәде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

**Бәйрәм кайтавазы**

Резедә Әбүбәкерова

# МИЛЛИ КИЕМ ТУЕ

**Буа**

**Буа Сабан туена халык милли бизәкле күлмәкләрдән, башларына калфак, түбәтәй, кокошник, масмак киеп, изү-алкалар тагып, чүәк-читекләрдән килде. Быел Сабантуйда милли рухка басым ясалган иде.**

Район башлыгы Ранис Камәртдинов Сабантуй капкасы саналган Карлы елгасы аша салынган күпердә кунакларны – Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыеваны, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаровны, Татарстан Дәүләт Советы депутатлары Шакир Ягудинны һәм Ринат Гайзатуллинны, Саха (Якутия) Республикасы Верхневилюйский улус (районы) башлыгы Владимир Поскачинны, Ульяновск өлкәсе губернаторы урынбасары Александр Коробконы, Казан шәһәрендәге Буа якташлыгы җәмгыяте рәисе Ирек Закировны, «Ак Барс» акционерлык җәмгыяте холдинг компаниясе генераль директоры урынбасары Айрат Туктамышевны һәм район үсешенә өлеш кертүче якташларыбызны каршылап, мәйданга чакырды. Мәйданга барып җиткәнче кунакларны районда бер гаиләдәй тату яшәүче төрле милләт халыкларының ишегалдына чакырды, үзенең гореф-гадәтен, мәдәниятен күрсәтте, көнкүреше белән таныштырды. «Татар өе»нә барысы да ишеккә өч тапкыр шакып, бусагага басмыйча уздылар. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаровка һәм башка кунакларга печән чабарга, мәчет манарасына ай куярга, «ишегалды»нда бәйләп куйган атны җигәргә тәкъдим иттеләр.

«Ат җигеп караганым юк иде әле», – диде министр, бахбайга камытны кигезгәндә. Премьер-министр урынбасары Ләйлә Фазлыеваны өлкәннәр үз куллары белән ясаган калфак һәм изүләр кызыксындырды. Ул бер калфакны киеп тә карады һәм аны, Буа Сабан туе кучтәнәче дип, үзенә бүләк тә иттеләр.

Чуаш, рус ишегалларында да төрле йолалар, тормыш рәвеше күрсәтелде. Алардан үткәнебез турында күп нәрсә белергә мөмкин иде.

Сабан туеның ачылыш тантанасы «Унике сугышчы кыз» риваятенә нигезләнгән иде. Театральләштерелгән тамаша аша бер мәлгә Буаның үткәненә «кайтып килдек». Халкыбыз хәтерендә хатын-кызларыбызның нәфисләген, тугрылыгын һәм матурлыгын данлаучы күп риваятьләр сакланган. Аларда туган җирләрен коллыкка төшерергә тырышучы илбасарларга каршы көрәшкән сугышчы кызлар турында күп сөйләнелә. Андый хатын-кызлар Буа төбәге тарихында да бар. Ата-бабаларыбыз килеп урнашкан җирләр куе урманнарга, җиләк-җимешләргә, кыргый җәнлек-кошларга, чишмәләргә бай булган. Әлеге байлыкларны, үз халкын саклау өчен, ир-егетләр, сугышка киткәндә, яшерен крепость төзегәннәр. Анда һәрберсенең үз шөгыле, һөнәре, осталыгы булган унике сугышчы кыз сакта торган. Күңелне тетрәндергән дә, соклandырган да, горурлык хисләре дә уяткан әлеге тамашаны йорттан йортка йөреп бүләк җыю, кыз урлау күренеше алыштырды. Мәйдан милли җыр-биюләрдән гөрләп торды. Алар тынуга тәбрикләүләр башланды. Беренче булып буалыларны һәм район кунакларын халкыбызның милли бәйрәме белән район башлыгы Ранис Камәртдинов котлады.

– Район халкына горурланырлык сәбәп бар: уртак тырышлык белән булачак уңышка ныклы нигез салынды. Хезмәтегез өчен зур рәхмәт! Сабантуйда күңелләрегез күтәренке булсын, ул районыбыз халкына күркәм эшләребезне гамәлгә ашыруда энергия, оптимизм рухы бирсен. Сезгә нык сәламәтлек, тынычлык, иминлек телим, – диде ул. Ранис Камәртдинов чакыруны кабул итеп, милли киемнәрдән, үз мәдәниятләре элементлары белән килүчеләргә рәхмәтен дә җиткерде. Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнехановның сәламләвендә дә моңа аерым басым ясалган иде.

Рәис котлавын Марат Җәббаров укыды. «Нәкъ менә Буада бәйрәмнең үзенчәлекле культурасы торгызылуны күрү шатлыклы хисләр уята. Биредә гасырлар дәвамында татар, рус, чуаш, мари, башкорт, азәрбайҗан һәм башка халыклар дус һәм тату яшиләр. Һәрберсенең кабатланмас традицияләре һәм матур костюмнары бар. Бүген бәйрәмгә аларны зур горурлык белән киеп килүчеләрне күрәбез», – дигән сүзләр бар иде сәламләүдә.

Тәбрикләүләр бүләкләүләр белән үрелеп барды. Сабан туе – иң элек хезмәт алдынгыларын данлау бәйрәме ул. Бу көнне дә авыл уңганнарының, югары игенчелек культурасына ия хуҗалыклар җитәкчеләре, белгечләренең урыны түрдә иде. Аларның татар, рус, чуаш милли костюмнарында бүләк алырга чыгуы үзе бер тамашага әверелде. Алдынгыларның күрсәткечләренә дә, бер-берсен кабатламаган милли киемнәренә дә сокланырлык, үрнәк алырлык шул.

Наилә ХӘСИПҖАНОВА
Әлфия ШӘРӘФЕТДИНОВА

«Татар-информ»

**Әлмәт**

Әлмәттә узган Сабан туенда Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты. Мәйданга җыелган халыкка ул Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның котлавын ирештерде.

Республиканың нефть башкаласында яшәүчеләрне һәм кунакларны бәйрәм белән котлап, Фәрит Мөхәммәтшин Әлмәтнең елдан-ел матурлануын һәм үсүен билгеләп үтте.

– Минем өчен Әлмәткә һәр килү – бәхет. Шәһәр аша Сабан туе урынына барганда, якташларым өчен тагын бер тапкыр горурлык биләп алды. Яңа йортлар төзелә, мәктәпләр һәм балалар бакчалары ачыла, спорт корылмалары арта, парклар яңартыла, урамнар төзекләндерелә. Моның өчен барыгызга да, бигрәк тә Әлмәткә генә түгел, бөтен республикага социаль ярдәм күрсәтү өчен бик күп эш башкаручы нефтьчеләргә рәхмәт, – диде ул.

Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә рәхмәтен әйткәч, Фәрит Мөхәммәтшин авылга аерым игътибар кирәклеген белдерде.

– Авылларны саклагыз, һәр хуҗалыкны, һәр ишегалдын кадерләгез һәм һәр кеше турында кайгыртыгыз, – диде ул район һәм авыл җирлекләре җитәкчеләренә. – Авыл республикабыздагы барлык халыкларның күпгасырлык традицияләрен, яшәү рәвешен, туган телен, мәдәниятен, милли киемнәрен саклый. Рус, татар, чуаш, мордва һәм башка халыкларның дус-тату яшәве төп байлыкларыбыздан берсе булды һәм шулай булып кала да.

**Балык Бистәсе**

Балык Бистәсе районының Олы Әшнәк һәм Кече Әшнәк авыллары Сабан туенда хатын-кызлар быел ир-атлардан рәхәтләнеп «үч алдылар»: камыт кидереп тә йөгерттеләр, зур ләгәннәргә утырып, мәйдан тирәли тарттырып та йөрделәр. Хәер, ирләре утырган ләгәнне үзләре яхшырак та өстерәделәр бугай әле. Чыннан да, көчле, уңган, булган кешеләр яши бу җирлектә.

– Кемнәндер көтеп ята торган гадәтебез юк, – ди авыл җирлеге башлыгы Резеда Хөснетдинова. – Егетләребез зур гына мәйданда печән дә чапты, урындыклар, багана, бүрәнәләрне дә үзләре төзеп куйдылар. Иганәчеләр дә – үзебезнеке. Ел саен ярдәм итүчеләр бар. Сорап торасы да юк. «Ярдәм кирәкме?» – дип үзләре килеп җитәләр. Шул исемлеккә яңалары өстәлеп тора, шөкер. Быел тагын бер үзенчәлек үзеннән-үзе пәйда булды. Сөлге җыйганда, кирәк булыр дип, авыл халкы акча да бирә башлады. Беренче ел булгач, шуларның барысына да балаларга уенчыклар алып, уеннар үткәрдек.

Бу Сабан туенда, инде ел саен кабатланып килсә дә, иң күңелгә тия торганы, мөгаен, 50 һәм 60 ел бергә тату гомер кичергән гаиләләрне котлау булгандыр. Юбилярлар янына балалары, оныклары чыгып баскач, мәйдан шау чәчәккә күмелде. Иң бәләкәй бәби белән, иң өлкән яшьтәге әбине дә «эзләп таптылар». Аларның берсе 3 айлык булса, икенчесе 91 яшьлек иде. Аларга да бүләктән өлеш чыкты.

Резеда ханым ел саен бәйрәмгә яңа бизәкләр кертергә тырыша. Быелгысы «Зәңгәр шәл» спектакленә яраштырып эшләнгән, авылдагы мәдәният хезмәткәрләре үзләре уйнаган сценарий иде. Абыстайларның Сабан туена барасы килә, ә Ишан хәзрәт каршы төшә. Ахыр чиктә җиңделәр. Әйтәм бит, хатын-кызлар бирешә торганнардан түгел бу авылларда. Монысы шаярту гына инде. Ир-атлар бер дә кимен куймый. Бу көнне тирә-юньне шаккатырып, бары тик Әшнәк авылында гына ат чабышы булды. Биш җайдак катнашты. Барысы да диярлек үзләренеке. Димәк, ат ярата торган чын ир-атлар яши биредә.

Әйтергә кирәк, Әшнәк авылларының кияү белән киленнәре дә сер бирә торганнардан түгел. Авыл халкын котларга килгән район башкарма комитеты башлыгы Данис Сатдинов Кече Әшнәк кияве булса, аның урынбасары Айгөл Вафина – шул авыл килене.

Ул көнне авыл чатларында җитәкчеләргә, оештыручыларга, иганәчеләргә – кыскасы, бәйрәмне матур итүдә катнашкан һәркемгә зур рәхмәтләр яуды. Аралашып торгач та бик рәхәт, бербөтен булып яшисең.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

**Яңа Тинчәле**

Былтыр Сабан туе барышында авылдашларына мөрәҗәгать итеп: «Киләсе елдагы милли бәйрәмебезне үткәрүдә тулысынча минем ярдәмгә өмет итә аласыз», – дигән иде ул. Крестьян-фермер хуҗалыгы җитәкчесе Фәнис Шәрәфетдинов вәгъдәсендә торды. Буа районының Яңа Тинчәле Сабан туе һәр елдагыча бүләкләргә, күңел ачуларга, көч сынашуларга һәм дә күңелле сюрпризларга бик бай булды. Яңа Тинчәледә бу бәйрәм дөньяга аваз салган, канат нык ныгытканнарның очрашу-хәтер яңарту көне дә әле ул. Гадәттә бу көнне Татарстаныбызның мөхтәрәм шәхесләре Радик, Ринат Гыйзатуллиннарның, Радик Хәсәновның Сабан туе чыгымнарын каплавына авыл халкы күнеккән иде инде, игелекле үрнәк дәвамчысын тәрбияләде, быел алар көтеп алган кунак буларак катнашты, авылдашлары белән сөйләшеп сүзләре бетмәде, фикерләре бер-берсенә ялганып, тулыланып торды.

Милли бәйрәмебез, алдан тәгаенләнгәнчә, төп-төгәл иртәнге сигездә башланды, тәбрикләүләр, хезмәт алдынгыларын бүләкләүләр менә-менә төгәлләнә дигәндә күк йөзендә болытлар пәйда булды һәм... зарыгып көткән яңгыр сибәләргә тотынды. Шуның белән бәйрәм рухына тагын бер куаныч өстәлде. Бәйрәме дә, яңгыры да бик кирәк иде.

Аннан авыл халкы район үзәгенә – Буага юл тотты. Район Сабан туе да шимбә көнгә билгеләнгән иде. Кичен исә яңатинчәлеләр авыл Сабан туен дәвам итте. Һич онытылмас, хәтердә әледән-әле яңарып торачак көн булды бу. Фермер Фәнис Шәрәфетдинов киләсе елда да Сабан туена бәйле барлык чыгымнарны да каплаячагын хәбәр итте. «Хезмәт сөючән, тырыш авылдашларыма, читтә гомер итүче мөхтәрәм яңатинчәлеләргә рәхмәтем, ихтирам билгесе бу, – диде ул. – Ил-көннәребез тыныч, исәнлектә-саулыкта, ирешелгәннәргә шөкер итеп яшәүләр насыйп булсын».

Яңа Тинчәле – республикабызның сокланып туймаслык, тарихи да, үзенчәлекле дә төбәге, «Бердәмлек» паркында узучы бәйрәмнәре дә үзенчәлекле, мәгънәле.

Габделбәр РИЗВАНОВ

**Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы**
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
**Тираж – 5315 данә**
**Гомуми тираж – 14253 данә**
**Газетага сертификат бирелде** Заказ 283

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
**www.vatantat.ru**
**info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru**
**89179270040**
**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)**
**П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)**
**П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)**
**П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР
**222-09-70** – кабул итү бүлмәсе
**222-09-67** – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
**222-09-73, 222-09-69, 222-09-65** – баш мөхәррир урынбасарлары
**222-09-68** – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
**222-09-67** – дин, сәламәтлек
**222-09-64** – әдәбият, сайт
**222-09-66** – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
**222-09-65** – реклама бүлеге
**222-09-72** – бухгалтерия
**222-09-73** – компьютер үзәге
**221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
**R** тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
**N** тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+